АВЫЛДАН КҮЧТӘНӘЧ

Шәһәр ярминкәләрендә 2,1 млрд сумлык продукция сатылган

> 2

БАЛАЛАР ТАВЫШЫ

Башкаладагы 16 нчы татар-инглиз гимназиясе 25 еллыгын бәйрәм итте

> 3

ИРАДА ӘЮПОВА:

«Тамашачыны алдарга ярамый»

> 4

КУБОК БЕЗНЕКЕ

«Зенит-Казан» волейболчылары Яңа елга җиңү бүләк итте

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 192 (28965) | Сишәмбе | 27 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

БАР ЫШАНЫЧ – ҮЗЕБЕЗДӘ

ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ ЕЛГА ЙОМГАК ЯСАДЫ

Җиңел булмаган елның нәтиҗәләре нинди? Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, гадәттәгечә, ел азагында журналистлар белән очрашты. Бу юлы Президент матбугат вәкилләрен Бәшир Рәмиев исемендәге яңа IT паркта кабул итте. 2022 елга ул нинди бәя бирә? Без кемгә ышанырга тиеш? Махсус хәрби операция һәм өлешчә мобилизациягә бәйле вазгыять кысасында нинди эшләр алып барыла? Президент мәктәп елларында форма киеп йөргәнме? Җәмигъ мәчете кайчан төзеләчәк? Очрашудан кызыклы өлешләрне тәкъдим итәбез.

2022 ел нәтиҗәләре турында

Үлчәп булмаса да, елның авырлыгын һәркем сизгәндер. Зур республикабыз Татарстан моны төрле яклап тойды. Президент Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, Көнбатыш санкцияләре аркасында, республика сәнәгать ягыннан алга киткән төбәк буларак кыенлыкларга юлыкты. Ник дигәндә, күп кенә компонентлар чит илдән кертелә иде. Үз продукцияңне тәкъдим итү өлешендә дә эш катлауланды.

– Яңа юнәлешләр табарга кирәк. Бу вазгыятьтә бар ышаныч – үзебезгә. Икътисадыбыз эшләсен өчен, бездә системалы эш барырга тиеш. Быел барлык кыенлыкларга да карамастан, без сәнәгать продукциясе күләме буенча да, тулай төбәк продукты буенча да артка китмәдек. Киресенчә, үсеш бар. Хәер, ул тагын да күбрәк булырга мөмкин иде, – диде Татарстан Президенты.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, инвестицияләр җәлеп итү һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендә куандырырлык нәтиҗәләр бар. Федераль һәм республикакүләм программалар дәвам итә. Үзәк ярдәмен дә тоябыз.

– Билгеләнгән барлык күрсәткечләргә ирешелде. Илкүләм һәм республика проектлары белән бәйле барлык бурычлар да үтәлде. Боларга, әлбәттә, республиканың барлык хакимият һәм федераль хакимият органнарының, муниципалитетларның, шулай ук безнең предприятиеләрнең җайга салынган системалы эше ярдәмендә ирешелде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Эшләгәнне күрсәтә дә бел. Яңалыкмы, үзгәрешме – барысын да халыкка җиткереп тору да кирәк бит. Бу җәһәттән Рөстәм Миңнеханов ел буе башкарган эшләрне язып, күрсәтеп, сөйләп торган матбугат вәкилләренә рәхмәтен җиткерде.

– Бүгенге максатым – сезне күрү һәм рәхмәт әйтү. Алга таба да иҗади хезмәттәшлек итәргә кирәк. Киләчәктә дә җиңел булмаячак. Әмма Аллаһы Тәгалә сынаулар белән шуларны уза алырдай кешеләрне генә сыный. Без дә – шундыйлар кавеменнән, – диде Татарстан Президенты. – Дәүләтчелекне лозунг белән генә түгел, эш белән күрсәтергә кирәк. Моңа үз өлешебезне барыбыз да кертергә тиеш. Шул исәптән, республика Президенты буларак, мин дә. Безнең башка юл юк.

Өлешчә мобилизация һәм махсус хәрби операция турында

Журналистлар телдән төшмәгән, уйдан китмәгән өлешчә мобилизация һәм махсус хәрби операция турында да Президентның фикерен белеште.

Республика җитәкчесе бу җәһәттән башкарылган эшләрне санап китте. Бу – мобилизацияләнгәннәрнең гаиләләренә ярдәм дә, балаларына аерым игътибар да, гуманитар яктан булышу, волонтерлар эше дә. Матди ярдәм янына рухи яктан терәк булу дигәне дә кушыла. Һәр җирлек, һәр шәһәр үзенчә тырыша, республика күләмендә карарлар кабул ителә.

– Мобилизация мәсьәләсе гади генә мәсьәлә түгел. Форсаттан файдаланып, хакимият вәкилләренә рәхмәт тә әйтәсе килә. Зур эш башкарылды, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Сүз уңаеннан, очрашу вакытында махсус хәрби операция зонасыннан сәлам дә килеп иреште. Рөстәм Миңнехановка «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хезмәт итүче каһарманнар видео әзерләп җибәргән иде. Президент сүзләренчә, махсус хәрби операция республика өчен дә яңа сынау булды. Әмма хәрбиләрне тәэмин итү, аларга булышу юнәлешендә республика куелган бурычларны үти алды.

Цифрлаштыру елы турында

Мәгълүм булганча, 2022 ел Цифрлаштыру елы дип игълан ителгән иде. Ел нәтиҗәле

tatarstan.ru

узганмы соң? Татарстан Президенты фикеренчә, сан белән санлашу турында сөйлибез икән, төп игътибар заманча җиһазларга да, инфраструктурага да, кешеләргә дә булырга тиеш.

– Акча гына түгел, бу эштә кешеләр дә мөһим бит әле. Белгечләрне әзерләргә кирәк, – диде республика җитәкчесе.

Цифрлаштыру димәктән, Татарстан әле олы юлның башында гына, ди Президент. Шулай да башкарган эшләр дә юк түгел.

– Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр санлаштырылды. Интернетка өч меңләп социаль-мәдәни корылма тоташтырылды. Цифрлаштыру җәһәтеннән эш дәвам итәчәк. Министр (Айрат Хәйруллин – Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры. – **Авт.**) миңа әйтте инде: бу ел нәтиҗәләре буенча без алдынгы урыннарда барабыз. Моңа кадәр хәлләр мөшкелрәк иде. Болар барысы да – системалы эш нәтиҗәсе, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов Республика клиник хастаханәсендәге яңалыкларны телгә алды, яңа төзелгән һәм очрашу урыны итеп сайланган яңа IT паркны да бу елның матур нәтиҗәсе рәтенә кертте.

Ахыры 2 нче биттә >

Татарстанда рәхәт

Татарстан тормыш сыйфаты буенча «РИА Новости» белгечләренең быел төзегән рейтингында дүртенче урынга чыккан. Республика барлыгы 68,184 балл туплаган. Анда төбәкләрнең социаль-икътисадый хәле, хезмәт базары торышы, халыкның матди хәле, фәнни-техник үсеш һәм төбәктә яшәүчеләрнең ни дәрәҗәдә сәламәт тормыш рәвеше алып баруы бәяләнгән.

Шулай итеп, рейтингта Мәскәү, 83,604 балл җыеп, беренче урынга чыккан. Икенче урында – Санкт-Петербург (81,769), Мәскәү өлкәсе (73,187) өченче урыны алган. Татарстаннан соң, Ханты-Манси округы – Югра бишенче урынга урнашкан. Сүз уңаеннан, ут күршебез Башкортстан – 13 нче урында (58,940). Исемлек ахырында – Ингушетия (23,590), ЕАО (22,851), Тыва Республикасы (21,497) иң ахырга калган.

Гомер озынлыгы арткан

Быел Татарстанда кан әйләнеше органнары авыруларыннан үлем-китем очраклары узган елдагы белән чагыштырганда 5 процентка кимегән. Сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков әйтүенчә, агымдагы елда 7 кан тамырлары үзәге яңа җиһазлар белән тәэмин ителгән. Шуның өчесе – Казанда, калганнары – башка шәһәрләрдә. Үзәкләрдә 380нән артыграк медицина җиһазы файдалануга тапшырылган. Яңа җиһазлар йөрәккә катлаулы операцияләрне күбрәк ясау мөмкинлеге бирәчәк. Министр әйтүенчә, инсульт кебек куркыныч чирләр һәм йөрәккә операция кичерүчеләр дарулар белән бушлай тәэмин ителә.

Республикада шулай ук яман чирне алданрак ачыклауга юнәлдерелгән профилактик чаралар тормышка ашырыла. Быел онкологиягә каршы көрәш буенча илкүләм проект акчасына Республика клиник онкология диспансеры һәм кайбер башка медицина оешмаларына заманча ПЭТ-үзәк җиһазы кайтарылган. Бөгелмә һәм Саба районнары үзәк хастаханәләрендә амбулатор онкология ярдәме үзәкләре ачылган.

10 айдагы мәгълүматларга караганда, Татарстанда уртача гомер озынлыгы 73,8 яшькә җиткән. 2022 елның пландагы күрсәткеченнән (72,2 яшь) артып киткән инде бу.

Күбрәк сатылган

Ел йомгакларына караганда, Татарстанның авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре чит илләргә барлыгы 367,9 миллион долларлык продукция саткан. Узган елдагы белән чагыштырганда 2,3 процентка күбрәк сан бу. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Рафаэль Фәттахов әйтүенчә, экспортка бигрәк тә май продукциясе күп җибәрелгән (255,5 миллион долларлык). 2021 елдагы белән чагыштырганда, чит илгә сатылган ашлык күләме – 30 процентка, ит һәм сөт продукциясе 2 тапкыр арткан.

Бездә җитештерелгәнне иң күп сатып алучылар булып Казахстан, Беларусь, Латвия, Германия, Үзбәкстан, Төркия һәм Польша санала.

Тузан төшермиләр

Быел гыйнвар – сентябрь айларында Татарстан Россия туристлары иң күп сәяхәт кылган төбәкләрнең берсе булган. Республика бу рейтингта 7 нче урынга чыккан. Росстат мәгълүматларына караганда, шушы чорда бездә 3,2 миллион сәяхәтче булып киткән.

Лидер – Краснодар крае (16,3 миллион турист). Шулай ук Ленинград өлкәсе (13,6 миллион), Мәскәү өлкәсе (13,4 миллион), Мәскәү (11,1 миллион) һәм Санкт-Петербург (6,4 миллион) туристларны мөкиббән иткән төбәкләр бишлегенә кергән. Кырым рейтингта алтынчы урынга урнашкан (3,6 миллион). Татарстаннан соң – Төмән (1,9 миллион), Свердловск (1,9 миллион) һәм Самара өлкәләре (1,7 миллион).

Суыта

Татарстанда томан һәм 17 градуска кадәр суык көтелә. Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, бүген явым-төшем ихтималы аз, юлларда – көчле бозлавык. Сәфәр чыкканда игътибарлы булыгыз!

Көндез термометрның төрекөмеш баганасы –7…–12 градус күрсәтәчәк (Казанда –9…–11). Төнлә –9…–14 (Татарстан башкаласында –12…–14) , урыны белән 17 градуска кадәр салкын.

Борчыган мәсьәлә

Бушаган шешәләр

Бер ел эчендә Россиядә шешә белән дуслашкан гүзәл затлар саны 7 процентка арткан. Бу хакта Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының Иҗтимагый сәламәтлек һәм балаларга медицина ярдәме департаменты җитәкчесе Елена Шешко хәбәр иткән. Татарстанда да саннар сискәндерә. Белгечләр фикеренчә, хатын-кызларга хәмердән зуррак куркыныч яный.

Рәсми мәгълүматларга караганда, бүген Россиядә 1,2 миллион кеше хәмергә бәйлелектән интегә. Ел дәвамында теркәлгән үлем-китем очракларының да күбесе әнә шул афәт аркасында килеп чыккан. Әйтик, бавыр таркалу, миокард инфаркты, панкреатит аркасында вафат булучыларның күбесе – хәмер белән мавыккан кешеләр, ди белгечләр.

Республика наркология диспансерының баш табиб урынбасары Илдар Таҗетдинов сүзләренә караганда, бүген республиканың наркология диспансерында эчкечелектән интеккән 30 меңгә якын кеше исәптә тора. Андыйлар саны ел саен 1–2 процентка арта бара. Татарстанда эчкечелек буенча исәптә торучыларның 70 процент чамасын – ир-атлар, калганын хатын-кызлар (!) тәшкил итә икән.

– Бүген бездә барлыгы 540 ятак урын исәпләнә. Шуларның 118е тернәкләндерү өчен каралган. Калган барлык койкаларда эчкечеләрне дәвалыйлар. Шул ятаклар арасында 46 койка – хатын-кызларныкы. Аларның беркайчан да буш торганы юк, – дип гаҗәпләндерде табиб.

Илдар Таҗетдинов фикеренчә, гүзәл затлар, нигездә, гаиләдәге проблемалар, эшсезлек, авырлыклардан качарга тырышып, шешәгә үрелә. Яшерен-батырын түгел: эчкечелек сазлыгына баткан хатын-кыз, гадәттә, бу начар гадәткә ияләшүен яшерергә тырыша. Эчкечелек юлына баскан кешеләргә инде 40 елдан артык ярдәм итүче тәҗрибәле табиб-нарколог Рөстәм Вәлиуллин моны аеруча куркыныч дип саный.

«Татар-информ»

– Хатын-кызның эчүе җәмгыятьтә кискен тәнкыйтьләнә торган начар күренеш санала. Шуңа күрә гүзәл затларның күбесе бу начар гадәтен яшерергә тырыша. Ачыкланганда инде хәлләр бик мөшкел – күпләр эчкечелекнең өченче стадиясенә җиткән була. Хатын-кыз организмында исерткеч эчемлекләргә бәйлелек ир-атныкы белән чагыштырганда 5–6 тапкыр тизрәк барлыкка килә. Ир-ат уртача ун елда эчкечегә чыкса, хатын-кыз ике ел эчендә дә сәрхушкә әйләнергә мөмкин, – ди ул.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Анатолий АКСАКОВ, Россия Дәүләт Думасының Финанс базары буенча комитет рәисе:

Киләсе 2023 ел җиңеллләрдән булмаса да, чагыштырмача күпкә әйбәтрәк тоелачак, чөнки без инде шок хәлендә калдырган төп санкцияләр чорын уздык, яңа шартларга ияләштек һәм яшәүгә сәләтле икәнлегебезне, киләчәгебез барлыгын исбат итә алдык.

(«Парламентская газета»га әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – МЕДИЦИНА БЕЛГЕЧЛӘРЕ

УРТА МЕДИЦИНА ПЕРСОНАЛЫ

45592

Шәфкать туташлары	30258
Фельдшерлар	3993
Фельдшер-лаборантлар	2333
Акушерлар	1496
Рентген лаборантлары	1031
Лаборантлар	171
Теш табиблары	168

** Татарстанстат мәгълүматлары нигезендә (2021 ел)*



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ДӨНЬЯ ИКЪТИСАДЫ: ЙОМГАКЛАР ҺӘМ ФАРАЗЛАР

Глобаль икътисадның хәле бүген күпчелек аналитикларны борчый һәм дулкынландыра, чөнки безнең киләчәк тормышыбызның туклыгы һәм матди тәэмин ителеше генә түгел, хәтта иминлеге дә шуңа бәйләнгән. Тирән рецессия зур сугышка китерергә мөмкин, матди хәле начарайган халыкларда гыйсъянчылык дәрте дә еш уяна. Бу факторлар бер-берсенә тыгыз бәйләнгән, бер җепкә тезелгән сәйләннәр кебек.

Үтеп баручы елның соңгы атналары бер дә сөендерми. Дөньякүләм рецессиянең котылгысызлыгына беркем дә шикләнми. Уртачыл карашлы икътисадчылар да күңелсез фаразлар ясый. Дөнья акцияләре һәм облигацияләре базары рекордлы суммада акча югалткан – 36 триллион доллар. Чагыштырыгыз: 2020 елда АКШ бюджетының керемнәр өлеше 5,9 триллион доллар тирәсе булган, Кытайныкы – 3,6 триллион, Россиянеке – 343 миллиардтан артыграк. Биржа спекуляцияләрендә күпме акча янганын шуннан күз алдына китерә аласыз.

Bloomberg агентлыгы белгечләре 2023 елны соңгы утыз елдагы иң начар ел булыр дип фаразлый. Аларның бу фаразы оптимистик та булырга мөмкин әле. Үтеп баручы 2022 ел да байтак фокуслар күрсәтте бит. Инфляция белән шаккатырды. АКШта ноябрьдә еллык инфляция 7,1 процентка җитте. Еврозонада октябрьдә үк инде инфляция күрсәткече 10,7 процент иде. Германиядә акча очсызлану 70 еллык тарихта иң куәтлесе булды: инфляция 11 процентка кадәр тизләнде. Балтыйк буе илләрендә 22 процентлык бәя үсеше тантана итә.

Газга бәяләр 1000 доллардан кыйммәтрәк йөрде, еш кына ике меңлек югарылыкны яулаган чаклары да булды. Менә шулар фонында фонд индекслары түбәнгә сикерде дә инде, спекулянтлар триллионлаган доллар акчасын җилгә очырды. S&P 500 биржасы индекслары ел башындагы 4800 пунктлык югарылыктан 3800гә кадәр түбәнәйде. Югалту – 20 процент тирәсе. Tesla компаниясе 55 процент капитализациясеннән колак какты. Apple, Microsoft, Alphabet, Amazon һәм Meta Platforms компанияләре барысы бергә 3,7 триллион долларлык кыйммәтләрен югалттылар.

Криптовалюталар тишеккә очты. FTX биржасы мәтәлчек атканда, без моның чылбыр реакциясе китереп чыгарачагын өзеп әйткән идек. Шулай булды да. Америка биржасы BlockFi һәм Австралия биржасы Digital Surge кычкырып бөлде. Genesis җитәкчеләре эшне туктату алдында тора. Биткоин бәясе 16 мең доллардан түбәнгәрәк китте, бу – соңгы ике елдагы иң түбән күрсәткеч.

2023 елда юнәлеш дәвам итәчәк. Барлык аналитиклар шул фикердә. Процент ставкалары үсү сәбәпле, банклар үзләрен яхшы хис итәр дип уйлыйлар, хәрби-сәнәгать комплексы акчага коеныр. Инфляция күрсәткечләре түбәнәер, билгеле. Әмма бу фәкыйрьлек башланганын хәбәр итәчәк.

Россиядә

ТӨБӘКЛӘР АКЧА СОРЫЙ

Беренче карашка Россия икътисады, тиңе булмаган санкцияләр чолганышында яшәп тә, үзен тотрыклы хис итә кебек. Март башында бәяләр кискен сикереп алганнан соң, инфляция дә артык туарылып китмәде, азык-төлек һәм товар дефициты да күзәтелми. Финанс системасы санкцияләр һөҗүменнән җимерелеп төшмәде, валюта курслары ел дәвамында диярлек тотрыклы торды. Эшсезлек дәрәҗәсе түбән. Эшкә кеше җитмәгән тармаклар да бар.

Илнең финанс резервларының яртысына якыны чит илләрдә туңдырылып калуын искә төшергәндә, хосусый капиталның да читкә чыгарылган күпчелек өлеше бикләнеп калуын да кушкач, икътисадның егылмый калуы гаҗәбрәк, билгеле. Росстат мәгълүматларын җентекләбрәк карасак, барысы да ал да гөл түгел икәнен күрәсең күрүен. Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ), россиялеләрнең өчтән бере тамакларын кыскан, ди әнә. Эчке тулай продукт алай кискен темплар белән кимемәде, әмма бу – хәрби-сәнәгать комплексының киеренке темпта эшләве нәтиҗәсе. Танк, снаряд, ракета һәм башка сугыш кирәк-яраклары күп җитештерелә, әмма килешик: безнең матди якны алар бөтәйтми. Сәнәгатьнең гражданлык тармаклары исә кискен түбәнәю кичерә. Автомобиль җитештерү сәнәгате быелның ун аенда 2021 ел дәрәҗәсенең 66 проценты күләмендә генә. Транспорт, машина төзелеше, двигательләр җитештерү, көнкүреш техникасы чыгару кискен кимегән. Сәбәбе аңлаешлы: комплектлаучы детальләр җитешми.

Чимал тармагында да күрсәткечләр түбәнгә тәгәри. Ташкүмер чыгару – 7, табигый газ чыгару 20 процентка диярлек кимегән. Киләсе елга нефть чыгару да кимер дип фаразларга сәбәпләр җитәрлек. Яшерен эшсезлек дәрәҗәсе югары. Кешеләрнең эш урыны саклана, әмма чынлыкта алар түләүсез ялда. Бер миллион тирәсе шундый хезмәткәр барлыгы мәгълүм.

Җитештерү генә түгел, куллану да кими. Ваклап сату сәүдәсе ун процентка кимегән. Статистика инвестицияләрнең торышы яхшы булуын күрсәтә. Тугыз ай нәтиҗәләре буенча үсеш – 6 процент. Әмма монда да нечкәлек бар. Хәрби-сәнәгать комплексына һәм аңа бәйле тармакларга инвестицияләр кискен артты, бу гомуми санны яхшырта. Эшкәртү сәнәгатенә, авыл хуҗалыгына, сәүдәгә, телекоммуникацияләргә инвестицияләр кими. Киләсе ел үсеше өчен зур өметләр багларга кирәкми дигәнне аңлата болар.

Катлаулы вазгыятьтә төбәкләр үзләренә күбрәк акча сорый. Россия Дәүләт Советының Икътисад һәм финанслар юнәлеше комиссиясе утырышында Финанс министрлыгы белән төбәк җитәкчеләре арасында бәхәс булып алды. Министр Силуанов төбәкләрне үз акылларына таянып яшәргә, федераль үзәктән сәдака көтеп утырмаска чакырды. «Без бит күреп торабыз: аерым төбәкләр реаль икътисад белән шөгыльләнәләр, ил буйлап, чит илләргә йөриләр, башкалар кул кушырып утыралар һәм югарыдан дотация көтәләр», – диде ул. Төбәк лидерлары үзләренә тәмәке акцизларыннан өлеш сорый, үзәк белән төбәкләр арасында төп бәхәс шул тирәдә бара. Силуанов исә нефть бәяләре 70 доллардан түбән булса, федераль хөкүмәтнең бурычка алып яшәргә мәҗбүр булачагын искәртә.

БАР ЫШАНЫЧ – ҮЗЕБЕЗДӘ

tatarstan.ru

Сөенечебез дә бар! Журналистлар белән очрашу барышында, Татарстан Президенты үзхәбәрчебез Рәшит Фәтхрахмановка «Татарстанның атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре» дигән мактаулы исемне тапшырды. Хезмәттәшебезне әлеге лаеклы бүләге белән ихластан котлыйбыз!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Лисичанск турында

Билгеле булганча, Татарстан Луганск Халык Республикасында урнашкан әлеге шәһәрне үз карамагына алды. Гуманитар һәм башка төр ярдәм дисеңме, республика бу җәһәттән нинди эш алып бара? Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, Татарстан Россия составына кергән яңа төбәкләргә терәк-таяныч булып тора, ярдәм итә.

– Шәһәр бик кыен хәлдә. Су, җылылык, электр буенча проблемалар бар, – диде республика җитәкчесе һәм халыкның көнкүрешен җиңеләйтү өчен башкарылган эшләрне санап китте. – Татарстан Лисичанскига махсус техника, транспорт һәм җиһазлар тапшырды инде, кышкы сезонга әзерлек вакытында күпфатирлы йортларны төзекләндерү өчен төзелеш материаллары даими озатыла. Хастаханәне төзекләндерү бара, белгечләр шунда җибәрелә. Гомумән әйткәндә, шәһәргә 1 мең тоннадан артык гуманитар ярдәм җибәрелде инде. Анда азык-төлек тә, кием дә, гигиена кирәк-яраклары, балалар уенчыклары, көнкүреш техникасы да бар. Бу эшкә районнар, бизнес, иҗтимагый оешмалар да кушыла. Балаларга ярдәм итү буенча аерым эш алып барыла. Гомумән, безнең әле эшлисе эшләр шактый. Кешеләрне игътибарсыз калдырырга ярамый. Рухи, матди таяныч мөһим һәм кирәк!

Җәмигъ мәчете турында

– Без Җәмигъ мәчете төзелеше өчен урын сайладык, әмма анда әле инженерия юнәлешендә эшләр башкарасы бар. Бу эш инде бара. Хәзер мәчетнең проектын сайлау буенча эш дәвам итә. Алар икәү – классик һәм заманча вариантлар. Бу арада кирәкле барлык карарлар кабул ителәчәк, киләсе елда инде төзелеш эшләре дә башланачак, – дип хәбәр итте очрашуда Президент. – Безгә бу эштә ялгышырга ярамый.

Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы турында

Киләсе елыбыз шул рухта узачак. Журналистлар ни өчен җитәкчелекнең нәкъ шушы юнәлешне сайлавы белән кызыксынды. «Сез әллә каршымы?» – дип, Президент та кызыксынып сорады. Журналистка җавап итеп исә:

– Бу карар республиканың үзенчәлеген саклау җәһәтеннән әһәмияткә ия. Ул Татарстанда яшәүче барлык халыклар өчен дә мөһим. Теләсә нинди карар мин шулай теләгәннән генә кабул ителми бит. Без фикер алышабыз, киңәшләшәбез. Безнең өчен хәзер нәрсә мөһим? Алга таба үсешебез мөһим. Әмма безгә генә хас үзенчәлекне дә саклыйсы килә. Без бераз гына заманчалашкан, бу бик үк яхшы түгел. Шуңа да бу карарны дөрес дип уйлыйм, – диде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КАЗАН ЧЫРШЫСЫ

Сагынып көттек ел буе. Республиканың Чыршы бәйрәме быел «Татнефть-Арена»да узды. Бирегә бөтен Татарстаннан 8,5 мең иң тырыш һәм актив балалар җыелды. Укуда, спорт ярышларында, иҗади бәйгеләрдә һәм иҗтимагый тормышта үзләрен яхшы яктан күрсәткән укучыларны Президент Рөстәм Миңнеханов котлады.

– Республика Чыршы бәйрәме ел саен Татарстанның барлык почмакларыннан меңләгән иң актив, уңышка ирешкән һәм талантлы балаларны җыя. Сезнең көчегез ирекле фикер йөртү, стандарт булмаган карарлар тәкъдим итүдә. Бу эштә сезгә мәктәп, спорт һәм иҗат түгәрәкләре, балалар һәм яшүсмерләр клублары, яшьләр берләшмәләре ярдәм итә. Сезгә тормышта үз урыныгызны табуыгызны телим. Иң мөһиме – артка чигенмәгез һәм бирешмәгез, – дигән теләкләрен җиткерде Президент. – Сезнең белән әти-әниләрегез, укытучыларыгыз, остазларыгыз, бөтен Татарстан. Сезгә ярдәм итәчәкбез һәм уңышларыгызга сокланачакбыз.

Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, балаларның казанышлары һәм тырышлыгы белән быел Казан Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Яшьләр башкаласы статусына ия булды, республика янә «Игелекле эшләр төбәге» һәм «Студентлар язы» Бөтенроссия бәйгеләренең җиңүчеләр исемлегенә керде.

– Киләсе ел республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Сез әби-бабайлардан калган милли гореф-гадәтләрне үстерү һәм бай тарихи мирасны саклап калуда, шулай ук мәдәниятне, туган телне өйрәнү буенча күп эш башкара аласыз, – диде Президент бәйрәмдә катнашучы балаларга.

Чара башланыр алдыннан төрле яшьләр оешмалары вәкилләре булган һәм Россия чемпионатларында һәм халыкара ярышларда катнашкан балалар Президент белән шәхсән аралашу бәхетенә дә иреште. Укучылар Рөстәм Миңнехановка үзләренең казанышлары турында сөйләде. Биергә һәм җырларга да өлгерделәр. «Республикадан китәргә исәбегез булмасын. Киткәннәр, укып бетергәч, әйләнеп кайтсын. Иң зур теләгем әнә шул», – диде Президент.

Катнашучылар арасында, активистлар һәм олимпиада җиңүчеләре генә түгел, авыр тормыш хәлендә калган, ятим, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар да бар иде. Шулай ук быел бәйрәмгә мобилизацияләнгән гражданнарның гаиләләреннән 2 меңнән артык бала чакырылган иде.

– Бу бик мөһим. Без барыбыз да могҗизага, теләкләрнең чынга ашуына ышанабыз. Бүген – ярдәм итү, Яңа ел могҗизалары вакыты, – диде Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева.

Бәйрәмнең төп персонажлары әкият геройлары булды. Мәңгелек кыйммәтләр – гаилә традицияләре турындагы хикәятне Яңа ел алдыннан әти-әнисе белән сүзгә килгән, тик соңыннан гаиләдән дә мөһимрәк нәрсә юк икәнен аңлаган Ваня исемле малай мисалында күрсәттеләр. Тылсымлы бәйрәмнең алыштыргысыз кунаклары – Кыш бабай белән Кар кызы да тамашага җыелган балаларның күңелен күрде. Бәйрәм тәмамланганнан соң, балаларга бүләкләр тапшырдылар.

Ләйсән САФИНА

ӘШЕ ДӘ БАР, АШЫ ДА

Президент көндәлеге

Әлмәттә бөтен җиһазы булган фатирларны кулланышка тапшырдылар, Түбән Камада урнашкан «ТАНЕКО»да яңача эшли башладылар, ә Яшел Үзән районы халкы сәламәтлеген яхшыртачак. Узган елларда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республиканың өч районына барып кайтты.

Әлмәттә Рөстәм Миңнеханов «Кванториум» балалар технопаркында булды. Президентка яңартылган корпусны күрсәттеләр. Биредә аэроквантум юнәлешен оештырганнар. Ул пилотсыз очкычларны проектлау, җыю һәм куллануга бәйле мәсьәләләрне хәл итүне күз уңында тота. Технопаркта Рөстәм Миңнеханов балалар белән дә аралашты. Ул аларга суднолар төзү заводына һәм КАМАЗга экскурсия оештырырга вәгъдә итте.

Нефть каласына эш сәфәре кысасында Президент балалар бакчасы булган күпфатирлы йортны да карады. Яңа фатирлар йорт җиһазлары, көнкүреш техникасы һәм беренчел кирәк-ярак белән тулысынча җиһазландырылган. Биредә «ТатНИПИнефть» һәм Әлмәт дәүләт нефть институты белгечләре наем нигезендә яшәячәк, дип фаразлана. 55 урынлы балалар бакчасы йортның беренче һәм икенче катларында урнашкан. Баланы бакчага өйдән чыкмыйча гына да кертергә мөмкин. Заманча балалар бакчасында сәнгать студиясе, логопедия, массаж, туган телне өйрәнү кабинетлары да бар. «Белгечләргә яшәргә уңайлы һәм җайлы булсын өчен, тиешле шартлар тудырачакбыз», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Әлмәттә «COLLAB DAY» фәнни-мәгариф конференциясе дә узды. Конференцияне Санкт-Петербург югары уку йорты белән берлектә Әлмәт дәүләт нефть институты оештырган. Аның эшендә Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Чарада IT өлкәсенең яшь лидерлары, фән белгечләре илнең фән һәм мәгариф өлкәсенә бәйле заманча проектлары турында фикер алышты.

«ТАНЕКО»да исә сынау рәвешендә хуш исле углеводородлар җитештерә башладылар. Тантаналы чарада Рөстәм Миңнеханов катнашты. Президент билгеләп үткәнчә, ароматика комплексы – нефть химиясе өлкәсендә мөһим проект. Ул «ТАНЕКО»га яңа базарларга чыгу мөмкинлеген тәэмин итәчәк. «Татнефть» һәм «ТАНЕКО» җитәкчелегенә, шулай ук барлык партнерларыбызга рәхмәтемне җиткерәм. Биредә ил җиһазлары файдаланыла. Без югары сыйфатлы продукт алачакбыз», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ароматика комплексы 8 технологик җайланмадан тора. Аларны 2018 елдан гамәлгә кертә башлаганнар. Яңа сәнәгать бензол җитештерүне елына 60 тоннага кадәр арттырачак, дип фаразлана. Елына 150 тонна параксилол җитештерүне дә җайга салмакчылар. Бу продуктлар чимал буларак «Татнефть»нең яңа сәнәгатьләрендә файдаланылачак.

Түбән Камага эш сәфәре барышында Рөстәм Миңнеханов быел «ТАНЕКО» проектын тормышка ашыру нәтиҗәләренә багышланган киңәшмә дә үткәрде. Президент сүзләренә караганда, әлеге проект республика өчен бик мөһим һәм санкцияләр булуга да карамастан, аны тормышка ашыру алга таба да дәвам иттереләчәк. «Бүген ачылган ароматика сәнәгате республиканың нефть химиясен үстерү өчен стратегик әһәмияткә ия. Мәсәлән, параксилол хәзерге вакытта чит илдән кайтарылучы чималны үзебездә җитештерә башлау мөмкинлеген бирәчәк», – диде Рөстәм Миңнеханов. Проектны тормышка ашыра башлаганнан бирле 109 миллион тонна нефть чималы эшкәртелгән. Төзелешкә 529 миллиард сум инвестицияләр җәлеп ителгән. «ТАНЕКО» комплексы – безнең горурлыгыбыз. Ул – ил күләмендәге проект. Без моны югары бәялибез», – диде Президент.

Яшел Үзән районында Рөстәм Миңнеханов «Дулкын» йөзү бассейнын ачу тантанасында катнашты. Район башлыгы Михаил Афанасьев әйтүенчә, бу – Васильево бистәсе халкы өчен зур шатлык. «Моңарчы Васильево игътибардан читтә кала килде һәм инфраструктура үсешенә сораулар туды. Әмма соңгы елларда бу бистәнең үсешенә игътибар бирәбез. Бассейн төзү мөмкинлеге чыккач та, мин Васильевоны тәкъдим иттем. Бассейнда шөгыльләнү өчен спортчы булырга кирәкми. Йөзү бик файдалы», – диде республика башлыгы. Рөстәм Миңнеханов «Драйв Парк» спорт-туризм үзәгендә дә булды. Президентка бистәдә тормышка ашырылучы инвестиция проектлары турында да сөйләделәр.

БӘРӘКӘТЛЕ СӘҮДӘ

Узган атнаның шимбәсендә көзге ярминкәләрнең соңгысы узды. Сер түгел, шәһәр халкы аны яратып, көтеп ала. Яңа ел алды булгангадыр, узган атнада халык ярминкә уза торган мәйданнарда аеруча күп җыелды. Кемдер ит тирәсендә кайнашса, кемдер балык, ысланган ризыклар тирәсендә мәш килде. Ярма, сөт ризыклары сатучылар яныннан да кешеләр өзелмәде – һәркайсында зур-зур чиратлар җыелды.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Мин бик көтеп алдым ярминкәләрне. Атна саен чыктым, – ди Казанда яшәүче Галия Ибраһимова. – Гадәттә чи балык, сыр, эремчек, казылык сатып алам. Күркә, тана ите алган чаклар да бар. Менә бу атнада Яңа ел табынына куярга үрдәк алырга чыктым. Язын гадәттә кыяр, помидор, йомырка, бәрәңге, яшел тәмләткечләр ала торган идем. Ярминкәләрдә бәяләрне ул дәрәҗәдә арзан дип әйтмәс идем, йомырканы, мәсәлән, кибеттә арзангаракка да алырга мөмкин. Тик сыйфат ягыннан ярминкәдә сатучылар алдыра. Авылдан килгән, фермерлар үзләре үстергән бит, дип сөенеп алам.

Илбар Сәгыйтдинов әйтүенчә, ул ярминкәгә ит алырга махсус йөри икән.

– Мин үзем генә яшим. Шуңа күрә итне ботлап алганым юк. Биш-ун килограмм алып куям да, үземә генә шактыйга җитә. Кайвакыт аны Адоратский урамындагы базардан алгалыйм, тик анда бик кыйммәт. Ярминкәдә ышанычлы да, арзанрак та. Тәмле дә. Үзебезнең татар егетләре саткач, гел күңелгә ятышлы. Мондый ярминкәләрнең файдасы бар дип уйлыйм. Халык күп йөри бит. Һаман да булып торсын иде әле, – ди ул.

Гомумән алганда, быел 19 марттан 23 апрельгә һәм 10 сентябрьдән 24 декабрьгә кадәр барлыгы 22 ярминкә узды. Алар Казанның – 15, Яшел Үзән районында һәм Чаллыда – икешәр, Түбән Каманың өч мәйданчыгында оештырылды. Ярминкәләр шулай ук 26 районда да үткәрелде. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хәбәр итүенчә, шушы көннәрдә 2,1 млрд сумлык продукция сатылган. 500 млн сумлык продукция – язгы, 1,6 млрд сумлык көзге чорда сатылган. Атна саен авыллардан 95 млн сумнан артыграк бәягә продукция алып килгәннәр.

– Ярминкәдә катнашучылар тырышлыгы белән сәүдә урыннарына 18 мең тонна яшелчә, шул исәптән 11 мең тонна бәрәңге, 1800 тонна ит, шул исәптән 1100 тонна сыер ите, 250 тонна сөт, 2 млн данә тавык йомыркасы, 655 тонна шикәр комы, 550 тонна он китерелде, – диделәр матбугат үзәгендә.

Кибет бәясеннән арзанрак, сыйфатлырак ризык сатып алу халык күңеленә хуш килә, әлбәттә. Фермерларга ярминкәләрдә сату отышлымы соң?

Арча районының Күпербаш авылында яшәүче фермер Альберт Галәветдинов итләрен «Казан» агропаркына алып килеп сата. Быелгы сатудан алар бик канәгать калган. Бер елда 20гә якын терлеген урнаштырган.

– Ярминкәгә теләсә нинди фермер да йөри алмый, чөнки бик мәшәкатьле эш. Башта малны сугым цехына алып барып чалдырырга, аннан соң машиналарга төяп алып барырга кирәк. Итне дөрес чабудан да күп нәрсә тора. Дөрес чабылмаса, алып барган ярты итне кире төяп алып кайтырга туры килүе бар. Без өч түшкәне сатып бетергәндә берне дә җибәреп бетерә алмаучылар да бар иде, – ди ул. – Эше авыр, аның каравы файдасы бар, тырышлык үзен аклый. Алып килгән ит җитми дә кала иде. Соңгы көнне аеруча күп сатылды. Инде үзебезнең сатып алучыларыбыз бар, кат-кат килеп, чират торып алып бетерәләр. Узып баручы ел бигрәк тә уңышлы булды. Халыктан бик күп рәхмәт сүзләре ишеттек.

Фермер әйтүенчә, халык бөтенесенә дә игътибар итә – итнең төсенә, исенә, сөякле булу-булмавына, кисәкләрнең зурлыгына. Итнең килосын 400–490 сумга сатканнар.

– Кемдер 15–20 килограмм ала, кемгәдер 2–3 килограмм да җитә. Атна саен ике түшкә алып килдек, артып калганы булмады. Бу – 600–700 кг ит дигән сүз. Соңгы атнада халык аеруча күп иде, 900 кг итебезне урнаштырып кайттык. Ничек сатып бетерербез икән, дигән шик юк бездә.

Альберт Галәветдинов безнең аша зур теләген дә җиткерде: Казанда атнасына бер генә тапкыр булса да фермерларга үз продукцияләрен сатарга мәйданчык бирелсен иде, ди ул.

– Алыпсатарларга арзан бәядән биреп җибәргәнче, фермерларга зур шәһәрләргә үзләренә килеп сату отышлырак. Шуңа күрә алга таба атнага бер тапкыр «Агропромпарк»ка яки башка мәйданга килеп сатар идем. Урын бирсәләр, бик яхшы булыр иде, әлбәттә. Даими клиентларыбыз да барлыкка килде, алар да көтә. Без продукцияне башкаларга караганда арзангарак сатабыз, шулай булуга карамастан, барыбер файдага була ул безгә. Халыкка да шулай яхшырак, – диде фермер.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТЕЛЕ БАРНЫҢ ЮЛЫ БАР

«Мин татарча укыйм»

Татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ бармы? Башкаладагы 16 нчы татар-инглиз гимназиясенең 25 еллык юбилеена багышланган бәйрәмдә бу сорауга икеләнергә дә урын калдырмыйча җавап бирделәр. Кайчандыр үзләре үк шушы уку йортын тәмамлаган, бүген исә исемнәре бөтен республикага таныш булган кешеләр гимназияне туган йорт белән чагыштырды. Әти-әниләр милли мохит турында горурланып сөйләде.

– Бүген гимназиядә 1218 укучы белем ала. Без микрорайон мәктәбе саналабыз. Шунлыктан гимназиягә микрорайон буенча безгә караган балалар килә. Алар арасында төрле милләт вәкилләре бар. Ничек кенә булмасын, 25 ел элек билгеләнгән юлдан тайпылмыйча – татар телле, милли рухлы балалар тәрбиялибез, – ди гимназия директоры Гөлфия Хәлимова.

Нәтиҗәсе дә күз алдында: ата-аналар балаларын бирегә шәһәрнең төрле почмакларыннан алып килә. Ишектән үк халкыбызга хас кунакчыллык, саф татар телендә исәнләшеп каршы алалар мәктәптә. Бәйрәмгә дә тел, мәдәният, гореф-гадәтләрне исәпкә алып әзерләнгәннәр әнә. Сәхнәгә Тукай да чыкты хәтта. Мәктәп укучылары Рабит Батулланың «Кылдан нечкә – кылычтан үткен» әсәреннән өзек күрсәтте.

– Бу гимназия Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән төзелгән. Биредә барысы да татар мохите тудыру өчен эшләнгән. Уку йортының максаты татар зыялылары тәрбияләүдән гыйбарәт. Мин үзем дә берничә ел биредә укытучы булып эшләдем. Хәтерлим: күршедәге 150 нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбендә балалар аз, ә монда күп булыр иде. Чөнки бирегә нәкъ менә татар телен өйрәнергә дип килделәр. Хәзер дә шулай. Монда чын мәгънәсендә татар мохите хөкем сөрә. Бүген Татарстанда «Адымнар» күптелле мәктәбе турында горурланып сөйлибез икән, әлеге эшнең орлыклары 25 ел элек шушы гимназиягә үк салынган, – ди Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының өстәмә һөнәри белем бирүне үстерү бүлеге җитәкчесе Роза Шәяхмәтова.

Татар-инглиз мәктәбе исәпләнсә дә, укучылар рус телен дә әйбәт үзләштерә. Үткән ел, мәсәлән, гимназия укучысы Әминә Кәбирова рус теленнән бердәм дәүләт имтиханын 100 баллга тапшырган.

Тинчурин театры артисты Гөлназ Нәүмәтова әйтүенчә, баланы татар теленә өйрәтү өчен беренче чиратта мохит кирәк.

– Бу гимназиягә икенче мәктәптән күчеп килдек. Беләсезме, бирегә килү белән, үз йортыбызга кергән кебек булдык. Монда якты йөз, тәмле сүз, бөтен җирдә чисталык-пөхтәлек күзгә ташлана. Бөтен әни-әниләр исеменнән укытучылар алдында баш иям, – диде ул.

Җырчы Иркә кечкенә кызларының сыйныф җитәкчеләрен икенче әниләре дип атады.

– Мин сәхнә кешесе булгач, гел гастрольләрдә йөрергә туры килә. Әтиебез кайда икәнне дә беләсез. Артур, мобилизациягә эләгеп, хәрби хезмәткә китте. Шөкер, кызларымны укытучылары әниләре кебек якын итеп, карап торалар. Бик зур рәхмәт аларга! Шатлык-кайгыларыбыз да уртак, без – бер зур гаилә, – ди Иркә.

Гимназиядә озак еллар татар теле һәм әдәбиятын укыткан, лаеклы ялдагы укытучы Резидә Сепперова әйтүенчә, милли йөзне саклап калу өчен, милли тирәлек булдырырга, мөмкин кадәр татар телендә аралашырга, туган телебездә фикер йөртергә кирәк.

– Бу уку йортын зур өметләр, зур хыяллар белән ачып кердек. Ул вакытта татар мәктәбе ачылуга халыкның соклануын күрсәгез иде. Мәктәп хәзер дә үз юлыннан тайпылмый. Биредә чын мәгънәсендә татар зыялылары тәрбияләнә. Гимназиягә юлым бервакытта да өзелмәде. Бүген мәктәптә ике оныгым укый. Аларның сөйләшүләреннән, сүз сөрешеннән, фикерләвеннән үк биредә яратып укыганнарын беләм. Безнең өчен моннан да зур бәхет юк, – диде ул.

Бәйрәм сәхнәсендә укучылар Кәрим Тинчуринның заманчалаштырылган «Беренче театр»ын да күрсәттеләр. «Театрга! Нәрсә төятергә? Баш төятергә!» – дип байлар йортында яшәүче Вәли белән Биби түгел, ә компьютер алдында утыручы җитәкче белән сәркатип әңгәмә корды. Бу да – телгә өйрәтүнең бер алымы. Заманасына күрә, хәзерге буынга яраклашырга да туры килә.

– Бүгенге заман укучысын туган телгә җәлеп итү, милләтенә карата мәхәббәт уяту өчен мәдәни эшчәнлекнең әһәмияте зур. «Нур» театр студиясе гимназия ачылган елдан бирле эшли. Туган илебезгә, туган телебезгә булган мәхәббәтне гимназия укучылары сәнгать аша җиткерә. Уңышларыбыз да шактый. Гимназия сәхнәсендә уйнап үскән балалар бүген Казан, Чаллы, Әлмәт театрларында эшли. Укучылар үзләре үк: «Мин татарча начаррак беләм инде, әмма өйрәнергә тырышачакмын», – дип сорап киләләр. Әле күптән түгел генә узган «Татар кызы. Татар егете» бәйгесендә классик әсәрләрне замана яшьләренә үтемле итеп куясы килде. Укучым, Камал театры артисты Артур Шәйдуллинга ярдәм сорап мөрәҗәгать иттем. Без гимназияне тәмамлаган укучылар белән даими элемтәдә торабыз, бу – хәзерге укучылар өчен дә бик яхшы үрнәк, – ди «Нур» театры җитәкчесе Роза Ибәтова.

Артур исә мәктәп елларына бәйле истәлеге белән дә уртаклашты.

– Мин укыганның эчтәлеген сөйли белми идем. Шуны белепме, әдәбият укытучысы гел исемлекнең иң ахырындагы Шәйдуллин фамилиясен әйтеп, мине такта янына чакырып чыгара иде. Бер «икеле» алдым, ике «икеле»… Аннары өйдә көзге каршына басып, эчтәлек сөйли торган булдым. Шул рәвешле сәнгатьле итеп сөйләргә дә өйрәндем. Һөнәр сайлауда әнә шул да ярдәм иткәндер, – ди Камал театры артисты.

– Татар телен өйрәнүгә ихтыяҗ, телебезнең, милләтебезнең киләчәге үзебездән тора, – ди Роза Шәяхмәтова. – Безнең өчен моны беркем дә эшләмәячәк. Үзебез туган телебездә сөйләшсәк, татар мәдәниятен белсәк, гореф-гадәтләрне сакласак, киләчәгебез дә булачак. Татар телен өйрәтү элек тә җиңел булмаган. Бөтен халыклар өчен дә шулайдыр. Татар җанлы, татар рухлы мәктәпләрдә балалар тавышы тынып тормаганда, киләчәгебез дә булачак.

Эльвира ВӘЛИЕВА



Фатих Сәйфи-Казанлы

Газетаның тарихын булдырган шәхесләрне барлауны дәвам итәбез.Фатих СӘЙФИ-КАЗАНЛЫ 1923–1925 елларда баш мөхәррир булып эшли. Татар тормышында зур роль уйнаган бу кешенең дә язмышы 1936 елның 16 сентябрендә кулга алыну белән тәмамлана.

Кайчандыр эсерлар партиясендә әгъза булып торганлыгын сәбәп итеп, аны хөкүмәт башлыкларына һәм партия җитәкчеләренә каршы һөҗүм әзерләүдә, милләтчелектә һәм башка шуның ише уйдырма «җинаять»ләрдә гаеплиләр. 1937 елның 3 августында СССР Югары Мәхкәмәсенең Хәрби коллегиясе үзенең ябык утырышында әдипнең «җинаять эше»н карап, аны иң югары җәзага – атарга хөкем итә. Хөкем карары ике көннән соң – 1937 елның 5 августында гамәлгә ашырыла. Җирләнгән урыны Казанның Архангел зиратында дип фаразлана.

Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин 1888 елның 22 мартында элекке Казан губернасының Спас өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Әлки районы) Карамалы авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа.

1891–1892 еллардагы ачлык вакытында аның әтисе Камалетдин агай гаиләсе белән Казанга күченеп китә һәм, шәһәрдә төпләнеп, башта ломовой извозчик хезмәте, соңга таба вак-төяк сату эшләре белән шөгыльләнә. 1916 елда ул, гаиләсен ияртеп, янәдән Карамалыга кайта һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда игенче хезмәтендә була.

Мөхәммәтфатих әүвәл Казанның мәхәллә мәктәпләрендә башлангыч белем ала, аннары «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Аны тәмамлагач, берникадәр вакыт Минзәлә өязендә җәдит ысулы белән укытыла торган мәктәпләрдә мөгаллим булып эшли, 1906 елда яңадан Казанга кайта да әдәби һәм журналистлык эшен башлап җибәрә. 1912–1918 елларда Уфа шәһәрендә яши. «Галия» мәдрәсәсендә тарих фәнен укыта.

1917 елгы Февраль инкыйлабы көннәрендә Фатих Сәйфи-Казанлы Уфада татар социалист-революционерлары (эсерлары) матбугат органы «Ирек» газетасының нашире була. Казанга әйләнеп кайткач, эсерлар белән араны өзеп, Мулланур Вахитов җитәкчелегендәге Мәркәз Мөселман комиссариатында эшли башлый. Гражданнар сугышы чорында ул Казандагы техникумнарда, хәрби-сәяси курсларда тарих һәм иҗтимагый фәннәр укыта. «Эшче», «Эш» исемле беренче татар совет газеталары белән актив хезмәттәшлек итә, РКП(б) әгъзасы итеп алына.

ТАССР төзелгәч, Фатих Сәйфи-Казанлыны, тәҗрибәле журналист һәм сәләтле оештыручы буларак, хакимият эшенә дә җәлеп итәләр: ул Татарстан Мәгариф комиссариатында, Җир эшләре комиссариатында җаваплы вазыйфалар башкара, 1923–1925 елларда «Кызыл Татарстан»ның (хәзерге «Ватаным Татарстан») һәм «Крәстиян гәзите»нең җаваплы мөхәррире булып эшли. Фатих Сәйфи-Казанлы татар язуын гарәп графикасыннан латин графикасына күчерү хәрәкәтендә актив катнаша, Татарстан Яңалиф җәмгыятенең рәисе һәм «Яңалиф» журналының җаваплы мөхәррире буларак, яңа язуны пропагандалауда һәм гамәлгә кертүдә иң күренекле рольләрнең берсен уйный.

Утызынчы елларда Фатих Сәйфи-Казанлы Татар коммунистлары университетында, Марксизм-ленинизм институтында һәм Казан Көнчыгыш педагогия институтында тарих фәненнән лекцияләр укый. Педагоглык эшенә бәйле рәвештә тарихи һәм иҗтимагый темаларга күп кенә гыйльми-популяр хезмәтләр яза.

Дәүләт оешмаларында, газета-журнал идарәләрендә җаваплы эшләр башкару, төрле уку йортларында лекцияләр уку белән бер үк вакытта, матур әдәбият мәйданындагы иҗади шөгылен дә туктатмый. Бу елларда ул бигрәк тә проза жанрында актив эшли. Әдип үзәк геройларны тасвирлаганда, аларның эш-гамәлләрен генә түгел, ә рухи дөньяларын һәм психологик кичерешләрен ачып бирергә омтылуы белән шул чордагы каләмдәшләреннән аерылып тора.

Фатих Сәйфи-Казанлы бу елларда татар классик әдәбиятын җыю һәм бастырып чыгару юлында да күп эшләр башкара. Аерым алганда, ул Габдулла Тукайның – өч томлык, Галиәсгар Камалның, Дәрдмәнднең бер томлык тупланмаларын төзеп чыгара. Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Сәгыйть Сүнчәләй иҗатларына багышланган махсус китап язып бастыра («Өч татар классигы турында»). Дөрес, авторның классик әдәби мираска мөнәсәбәте шактый каршылыклы була. Вульгар социологизм йогынтысына бирелеп, әдәби мираска карата дөрес булмаган «үтә сул» фикерләрен әйтеп чыга.

1934 елның августында СССР язучыларының Мәскәүдә узган I съездында Фатих Сәйфи-Казанлы Татарстан делегатларының берсе буларак катнаша. Ул аннан рухланып, үз сүзләре белән әйткәндә, «язучылык профессиясенең социалистик илне төзүдә җаваплылыкта инженердан, архитектордан, профессордан, җаваплы совет эшчесеннән – гомумән, җаваплы эшченең һичберсеннән ким түгеллегенә тирән ышанып», эшкә зур дәрт һәм яңа әдәби иҗат планнары белән әйләнеп кайта. Әмма инкыйлабның беренче елларыннан ук яңа хакимияткә хезмәт итүне үзе өчен намус эше итеп санавына, Октябрьне ихластан кабул иткән татар язучыларының барысыннан да диярлек артыграк дәрәҗәдә тырышып, совет идеологиясен пропагандалауга, аның сәясәтен гамәлгә ашыруга бөтен көч-сәләтен куюына карамастан, тоталитар режимның утызынчы еллар ахырындагы «олуг террор»ы Фатих Сәйфи-Казанлыны да үзенең тегермәненә салып тарта.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

Бушаган шешәләр

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Белгечләр борчуга салырлык тагын бер сан атый. Бер ел эчендә Россия авылларында эчкечелектән интегүчеләр саны да 7 процентка арткан. «ВТ» хәбәрчесе элемтәгә кергән белгечләр бу уңайдан да фикерен җиткерде.

Рөстәм Вәлиуллин фикеренчә, авыл җирендә яшәүчеләр арасында эчкечелекнең тамыр җәюе халыкның бүгенге күңел халәтенә бәйле.

– Соңгы арада дөньяда, илдә барган вакыйгалар күпләр тормышының астын өскә китерде, җәмгыятьтәге киеренкелекне арттырды. Кагыйдә буларак, стресс арткан җирдә исерткеч эчемлекләр дә күбрәк кулланыла. Мәсәлән, 1990 нчы елларда да бик каты эчәләр иде. Моңа, нигездә, тормыш дәрәҗәсенең түбәнлеге, эшсезлек сәбәпче булды. Бүгенге тотрыксыз тормыш, шул ук эшсезлек кабат теңкәгә тия. Инфляция бик зур. Кеше акча җиткерә алмый. Көн дә ишетелеп торган күңелсез хәбәрләр дә кешенең психофизиологик халәтенә тискәре йогынты ясый бит. Кеше, аз булса да онытылыр, киеренкелектән котылыр өчен, хәмергә үрелә, – ди табиб-нарколог.

Психотерапевт, «Яшәү территориясе» социаль инициативалар үзәге башлыгы Антон Миронов фикеренчә, шәһәрдә дә, авылда да эчкечеләр саны елдан-ел арта бара һәм моңа гаҗәпләнергә кирәкми. Белгеч сүзләренә караганда, соңгы арада аларга ярдәм сорап килүчеләр арасында наркоманнар да күбәеп киткән.

– Күреп торабыз: илдә – кризис. Шуңа хәзер мобилизация, чикләүләр өстәлде. Күпләрнең киләчәккә планнары җимерелде. Халыкның керемнәре кимеде. Кереме кимемәгәннәрнең чыгымнары артты. Тормыш кыйммәтләнде. Элек бер сум торган әйбер бүген 5 сумга төшә. Мондый негатив, тормыш авырлыгы кешене акрынлап баса. Күпләр андый чакта беренче эш итеп шешәгә үрелә. Шәһәр җирендә ул яктан барыбер җиңелрәк әле. Каядыр барып кайтырга, бераз онытылырга, күңел ачарга мөмкин. Авылда – үле тынлык. Шуңа кеше төшенкелеккә дә тизрәк бирешә. Һава торышына каршы көрәшеп булмаган кебек, эчкечелекне дә җиңәрлек түгел. Бар да илдәге вазгыятькә бәйле. Тормышлар җайланып, илләр тынычланып, социаль проблемалар кимесә, илдәге эчкечеләр саны да азаер иде, – ди белгеч.

Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) белгечләре тарафыннан уздырылган соңгы тикшеренү нәтиҗәләреннән аңлашылганча, бүген ил халкының өчтән бер өлеше хәмер белән дус түгел. Сораштыру барышында респондентларның 31 проценты – исерткеч эчемлекләрне гомумән кулланмавын, 69 проценты ара-тирә тоткалавын әйткән. Белгечләр, ил халкы арасында иң популяр исерткеч эчемлекләр – аракы (59 процент), сыра (48 процент) һәм шәраб (21 процент), дип нәтиҗә ясаган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ИКЕ ШУБАНДА – АЛТЫ ТУГАН

Язмыш

Авыл атамалары арасында бер үк исемдәге, әмма Югары, Урта яки Түбән, Яңа яки Иске, Зур яки Кече дигән өстәмәсе булганнары шактый. Безнең Балтач районында да дистәләп алар. Мондый атамалар һәр районда бар. Гадәттә, әлеге авыллар бер-берсенә бик якын урнашкан һәм аларда бер үк нәселдән булган гаиләләр дә еш очрый.

Балтач

Бу кадәресе күп очракта төп авылдан күченеп, яңасына нигез салучылар белән бәйле. Алар яңа исем эзләп азапланмаган, берәр сүз өстәгән генә. Ике авыл арасындагы бәйләнеш тә өзелмәгән, алай гына да түгел, еллар үткән саен арта, ныгый гына барган. Бәлки, шуңадыр да авыллар исемендәге якынлык, кабатлану еш кына алар арасындагы җылылык, дуслыкка да нигез була. Без, мәсәлән: «Ике Салавыч инде күптән кушылып беткән булыр иде, арада Шушма елгасы һәм язын су астында кала торган болын гына аерып тора», – дибез. Безне күп нәрсә берләштерә.

– Без дә гомер буе бергә, – ди районыбызның Түбән Шубан авылында яшәүчеләр дә. – Бергә укыдык, эшләдек, бергә яшәдек. Бер авыл кебек. Шунда башка чыккан туганнарыбыз бар. Ике авыл арасындагы аерманы уйлаган да юк, кем Түбән Шубаннан, кем Югары Шубаннан, дип тормыйбыз…

Төп чыгышлары Түбән Шубаннан булган Хәсәновларның да әнә өчесе күрше Шубанга төпләнгән. Алты баланың алтысы да авылда калган бу гаиләне «авылның йөзек кашы» дип тикмәгә генә әйтмиләр булып чыкты. Миңа ике килендәш – Рәзинә һәм Нәфыйга белән күрешеп сөйләшергә туры килде. Икесе дә шушы авыл кызлары. Рәзинә – төп йорт килене. Икенче бала булган Нурлыхакның тормыш иптәше.

– Нурлыхаклар алты бала.

Хәсәновларның гаилә архивыннан

Олылары Габделхакка – унсигез, төпчекләре Зөлхиягә яшь ярым булганда әти-әниләре, бер-бер артлы авырып, үлеп китә. Башта өч ел аларны әтиләренең әнисе Маһиҗиһан әбиләре тәрбияли. Ул иң авыр чакларында балаларны берләштерә, аларга әти дә, әни дә була. Өлкән балаларда туганлык хисләрен ныгыта. Шөкер, шушы хисне алар гомер буе саклый белде. Бер-берсенә бик туганчыл, ярдәмчел булып үсәләр, яшиләр. Тик Маһиҗиһан әби өстендә әле тагын бер йорт, тагын балалар була. Аңа бик кыен икәнлеген аңлап, мәрхүмә әниләренең апасының биеме, ягъни каенанасы Мәүлизә әби, шушы йортка күчеп килеп, балаларны үз канаты астына ала. Кечерәк балалар Зәкәрия белән Зөлхияне сорап та киләләр, әмма Мәүлизә әби аларны беркемгә дә бирми, бер-берсеннән аермый. Аларны үстерә, шушы йортта малайларны зурлап өйләндерә, кызларны кияүгә бирә. Без әле аның белән җиде ел бергә яшәдек. Бүген дә аның балалары, балаларының балалары белән бертуганнар кебек аралашып яшибез… – дип сөйләде Рәзинә.

Хәсәновларның өчесе – Түбән Шубанда, өчесе Югарысында төпләнә. Габделхак гомере буе комбайнчы булып эшләгән, заманында күп макталган, җәмгате, шулай ук дистә еллар алдынгы сыер савучы Халидә белән дүрт бала тәрбияләп үстергәннәр, бүген лаеклы ялда. Нурлыхак та – данлыклы комбайнчы, пенсиядә булса да, быел да кырда эшләгән әле. Башлангыч сыйныф укучыларына белем биргән Рәзинәсе белән бергә матур гомер кичереп, ике бала үстергәннәр. Төп нигезне саклаучы да, ишле нәселне бергә туплап тотучы, һәркемне ачык йөз, тәмле сыйлар белән каршы алучы да алар.

Балалар бакчасында эшләп, лаеклы ялга чыккан Зөлфия һәм гомер буе тракторда эшләгән тормыш иптәше Ринат, хуҗалыкта озак еллар комбайнчы, тракторчы, эретеп ябыштыручы булып эшләп, лаеклы ялда булса да, быел да абыйсы Нурлыхакта комбайнчы ярдәмчесе булган Гаделхан һәм утыз ел балалар бакчасында эшләгән Нәфыйга гаиләсендә дә өчәр бала үсеп, башлы-күзле булган. Тырыш нәселнең дәвамчылары шактый, барысы да әти-әниләре кебек уңганнар, булганнар.

Хәсәновларның төпчекләре – Зәкәрия белән Зөлхия дә абыйапаларыннан калышмый. Шәхси «КамАЗ»ы белән хезмәт күрсәтүче Зәкәриягә авылда бик күпләр рәхмәтле. Тормыш иптәше Чулпан – балалар бакчасы мөдире. Ике балалары да гаиләле.

Зөлхия исә мәктәптә пешекче, җәмәгате Наил – «Алга» хуҗалыгында прораб. Аларда да – өч бала, берсе өйләнгән. Маһиҗиһан, Мәүлизә әбиләре, әнә шулай алты ятимгә күңел җылысы гына биреп калмаганнар, эш яратырга да, туганлык хисләрен ныгытырга да өйрәткәннәр. Үзләренә догачы балалар, оныклар калдыра алган олы җанлы бу әбиләрне авылдашлары да хөрмәт белән искә ала. Моңа гаҗәпләнергә дә кирәкмидер…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии с Постановлением Правительства № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Министерства промышленности и торговли Республики Татарстан https://mpt.tatarstan.ru/ao-tatenergosbit.htm и АО «Татэнергосбыт» https://tatenergosbyt.ru/about/open-info/market-subject/investment-info/ размещена в полном объеме информация об итоговом проекте инвестиционной программы АО «Татэнергосбыт» на 2023–2025 гг.

Свидетельство серии 16 номер 89692 от 24.03.2021, выданное ООО «Драйв» на имя Моисеичева ДамираИрековича, считать недействительным в связи с утерей.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Спорт

zenit-kazan.com

Унберенче җиңү

Гадәттәгечә. «Зенит-Казан» волейболчылары Яңа Уренгойда Россия Кубогын яулады. Бу – Татарстан командасының 11 нче җиңүе. Соңгы 9 елда Казан клубы Россия Кубогына 8 мәртәбә ия булды.

«Зенит-Казан» 10 мәртәбә Россия чемпионы булып танылды, әмма якташларыбызның инде 4 ел дәвамында алтын медаль ота алганы юк. Ә менә Россия Кубогын Казан командасы башкаларга бирми. 2014 елдан бирле якташларыбыз әлеге турнирда бер генә мәртәбә оттырды. Узган атна ахырында Яңа Уренгойдагы чирекфиналда да «Зенит-Казан» төп фаворит саналды.

Ярымфиналда безнекеләр «Белогорье» белән очрашты. Алексей Вербов командасы көндәшен 3:0 (25:23, 25:22, 25:15) исәбе белән отты, әмма беренче ике сетта көрәш ахырга кадәр барды. Хәлиткеч уенда исә якташларыбызга җирле «Факел» белән очрашырга насыйп булды. Дөресен әйткәндә, көндәшнең бердәнбер өстенлеге матчның аларның мәйданында узудан гыйбарәт иде. Тик ул гына ярдәм итмәде. Шуңа күрә финал безнекеләр өчен ярымфиналдан кулайрак булып чыкты һәм «Зенит-Казан» 3:0 (25:16, 25:14, 25:21) исәбе белән җиңүгә иреште.

Шулай итеп, Казан командасы үз тарихында 11 нче мәртәбә Россия Кубогына ия булды. Алдагы финалларда якташларыбыз Мәскәү «Динамо»сын (2004, 2007, 2021), «Локомотив»ны (2009, 2014, 2016), «Белогорье»ны (2015), «Кузбасс»ны (2017) һәм Санкт-Петербург «Зенит»ын (2018, 2019) җиңгән иде.

Дәүләт Советы Рәисе, Татарстанның Волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин «Зенит-Казан» командасы җитәкчелеген, уенчылар һәм тренерларын Россия Кубогында җиңү белән котлады. Парламент җитәкчесе клуб президенты Рәфкать Кантюков, баш тренер Алексей Вербов, «Динамо-Татарстан» физик культура һәм спорт җәмгыяте рәисе Әсгать Сәфәров, «Газпром трансгаз Казань»ның генераль директоры Рөстәм Усманов исеменә телеграмма юллады.

«Безнең егетләр ышанычлы рәвештә искиткеч җиңүгә иреште һәм ил волейболында лидер булуларын кабат раслады. Җиңүнең бәхетле мизгелләре, Татарстан волейболының тантанасы өчен рәхмәт сезгә», – диелә телеграммада.

Фәрит Мөхәммәтшин әлеге җиңүдә Әсгать Сәфәровның өлешен аерым билгеләп узган. «Республикада спортны үстерүдә актив ярдәм һәм игътибарыгыз нәтиҗәсендә иң югары казанышларга ирешәбез. Әлеге җиңү җанатарлар өчен Яңа ел бүләге булды», – дигән ул.

Язучы сүзе

Сүзләр йөри

Дөнья күктән, җирдән һәм сүздән тора. Ә тагын кешеләр бар икән әле. Аларның берише күккә битен күрсәтә, берише – бүтән җирен. Ә сүзне барысы да сөйли. Белсә дә, белмәсә дә, күрсә дә, күрмәсә дә... Телнең кыйбласы юк.

Вәт. Менә авылга кайтам. Мин инде монда көтеп алынган кунак. Һәрбер сүзем – яңалык. Бик гади кеше түгел бит инде, простой халык бик иснәнеп тә борынын тыга алмаган җирләргә үтә ала торган кеше. Үзе дә үтә, сүзе дә үтә торган. Вәт, менә мин авыл гайбәтчеләре өчен табыш инде. Сораштырасылары килә. Сораштыралар.

– Былтыр фәлән-фәлән кеше үлгән иде бит, – диләр. – Аны, үз үлеме белән үлмәгән, дип сөйлиләр. Зинһар, әйт инде, пажалысты, безнең өчен генә. Ул үз-үзенә кул салганмы, әллә аны үтергәннәрме?

– Юк, – мәйтәм, – үз үлеме белән үлгән.

Халык ышанмый. Аның фикеренчә, я аны үтерергә тиешләр, я ул... Ну, аңлашыла инде. Кино карап, китап укып үскән кешеләр бит, бөекләрнең гади бәндә үлеме белән китүләренә ышанасылары килми. Йөрәге тотып, ашказаны авыртып, я эче китеп үләргә тиеш түгел бит инде бөек кешеләр. Аларның үлеме дә бөек булырга тиеш.

Моны сөйләп тә бетермибез, икенчегә күчәләр:

– Ә менә фәлән-фәлән җырчының ире өстеннән йөргән икән, ул шуңа асылынып үлгән икән... Дөресме шул?

– Дөрес түгел.

– Нигә дөрес түгел?

– Чөнки ул фәлән-фәлән җырчы әле исән.

– Кайдан исән булсын инде, телевизордан гел иске язмаларын гына күрсәтәләр бит.

– Ул әле декрет ялында. Бәби карый, шуңа яңа җырлар эшли алмый.

– Ничек инде декрет ялында? Үлгән кешеме?

Мин шаяртырга маташам.

– Әйе. Хәзер бит авырлы килеш үлсәң, декрет ялы бирәләр.

Ә тегеләрнең үз туксаны туксан:

– Ничек?! Ул үз хатыны авырлы булган килеш чит хатын белән йөргәнмени?!

– Әле җитмәсә, аның шул читтәге хатынында баласы да бар, дип әйтәләр.

Мин инде шаяртуның соңгы чигенә җитәм. Хәзер үзем дә белмим инде шаярту микән бу, нерв җепселләренең берәр төрле тартышуы микән:

– Әйе, аның читтә сөяркәсе бар, шул сөяркәсеннән баласы бар. Хатыны шуның өчен асылынып үлгән. Һәм әле бәби үстереп ята.

Хәзер боларның күзе маңгайга менә:

– Ничек инде үлгән килеш бала үстереп ята?

Бер акыллысы шундук җавап таба:

– Андыйларны зиратка кертмиләр бит, кая барсын инде...

Ул арада тагын да акыллырагы район үзәгеннән урлап кайткан афишаны ачып җибәрә:

– Менә! Бер атнадан ул безгә концерт белән киләчәк!

Төркем тынып кала. Шуннан кемдер әйтеп сала:

– Вәт әй, ә! Үлгән килеш тә концерт куеп йөре инде, ә.

– Җитмәсә дә җитми икән кешегә акча.

Минем акыл бу сүзләрне сөреп чыга алмый. Ул арада үземә бәйләнә башлыйлар:

– Карале, ник син авылга гел бер хатының белән генә кайтасың ул?

– Әйе, санга сукмыйсың, что ли? Ә безнең бәлки җидесен дә күрәсебез киләдер.

– Юк, мин синең урыңда булсам, куркып тормас идем. Ну, дан бар, мал бар... Кайт инде ияртеп бөтенесен дә.

Беркадәр вакыт узганнан соң, сүзләр бераз үзгәрәчәк. Монда озаграк торсам, җиде хатынымнан да аерылган икән дип сөйләячәкләр. Кайчагында хәтта әни дә шикләнеп сорап куячак:

– Улым, килен берәү генәме ул?

– Улым, аерылышмадыгызмы?

Дөнья җирдән, күктән һәм сүздән тора. Һәм кешеләрдән. Җир дә, күк тә, сүзләр дә үзгәрә. Ә кешеләр беркайчан да үзгәрми. Үзгәрмәячәк тә. Кешеләр әллә нәрсәләр сөйләячәк. Шуңа күрә мин барыгызны да алдан кисәтеп куям. Беркайчан да бернәрсәгә дә ышанмагыз. Хәтта мине үлгән дисәләр дә. Ышанмагыз. Үзем сезнең күзегезгә карап: «Мин үлдем», – дип әйтмәгәнмен икән, димәк, мин исән.

Марат КӘБИРОВ

ЕЛЫНА КҮРӘ ЧАРАСЫ

Нәтиҗә

Хисапларсыз, рәсми саннарга тукталып тормый гына дуслар-ча сөйләшү. Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпованың Яңа ел алдыннан узган журналистлар белән очрашуын ике-өч сүз белән әнә шулай тасвирлап була. «Соңгы арада мин болай да күп сөйләшәм», – дип, бу юлы министр журналистларны тыңлыйсы итте.

tatarstan.ru

Очрашу «Искусство жить» мәдәни-агарту үзәгендә узды. Октябрьдә генә эшли башлаган әлеге үзәктә әдәбият, кино, музыка, рәсем сәнгате, мода һәм фәлсәфи темаларга багышланган төрле очрашулар, лекцияләр, остаханәләр уза икән. Әлеге оешманың дәүләттән акча сорамыйча да уңышлы эшләве искәртелде. «Бездә социаль юнәлештәге эшкуарлык мәйданчыклары арта бара. Мин моңа бик сөенәм», – диде Ирада Әюпова. Шуннан соң журналистларга 2022 елда мәдәният өлкәсендәге иң истә калырдай чараларны атарга кушты.

Театр

Иң беренче булып Камал театрындагы «Көл» спектакленең премьерасын атадылар. Без аның турында язган идек инде. Мәдәният министры үзен әсәрдәге Автор образы белән чагыштырды, Айдар Җаббаров куйган спектакльгә һәрьяклап уңай бәя бирде. Театр өлкәсендәге ел вакыйгалары исемлегенә Качалов театрындагы «Секрет ее молодости» спектакле дә керде. Ирада Әюпова Казан Яшь тамашачы театрының юбилей сезонында уздырган чараларын да билгеләп узды. Моннан тыш, Болгарда ачык һавада куелган «Кара пулат»ның да журналистлар күңелендә аерым урын алып торуы ачыкланды. Министр да шул ук фикердә булып чыкты.

Кино

Ел вакыйгалары исемлеген быелгы Казан халыкара мөселман киносы фестивале тулыландырды. Ләкин Ирада Әюпова бу фикер белән бик килешеп бетмәде.

– Мәдәният өлкәсендә уздырыла торган һәр чараның үз концепциясе, фәлсәфәсе булырга тиеш. Ә мөселман киносы фестивалендә ул юк. Минемчә, Миләүшә Ләбибовна төрле юнәлешләрдә эшләп карый, эзләнә. Омтылышлар бар. Ачылу һәм ябылу тантаналары кызыл келәмнәр белән зурлап үткәрелә. Әмма фестивальнең асылы кызыл келәм түгел, ә аның кысасында уздырыла торган фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу, – диде министр.

Эстрада

Бераздан аралашу сорау – җавап рәвешен алды. «Үзгәреш җиле» нәрсә дә булса үзгәртәме? Журналистларның Ирада Әюповага биргән сорауларының берсе шундый иде. Сүз уңаеннан, әлеге фестиваль быел җиденче мәртәбә уздырылды.

– Миңа калса, «Үзгәреш җиле», беренче чиратта, эстрада үсешенең гомуми концепциясен үзгәртте. Моннан 10 еллап элек артистлар фонограммага җырлау белән мавыкса, хәзер эстрадада тере тавыш ешрак яңгырый, – диде министр. – Беләсезме, мин болай уйлыйм: әгәр журналист теге яисә бу концерт турында яза икән, ул артистларның фонограммага яки тере тавышка җырлавы турында да язарга тиеш. Җырчы да сәхнәгә чыга икән, «Мин фонограммага җырлыйм», – дип, ачыктан-ачык әйтсен. Тамашачы һәм җырчы арасында ышаныч шул вакытта гына булачак. Эстрада – мәдәниятнең халыкка иң якын тармагы. Ә халыкны алдарга ярамый.

Рухият

Арабыздан бер журналист Казан циркында намаз уку бүлмәсенең ни өчен кирәк булуын да сорады.

– Минемчә, монда бәхәсләшер өчен урын юк. Намаз уку бүлмәләре аэропортта да бар, мин моны гадәти хәл дип уйлыйм, – дип җавап бирде Ирада Әюпова. – Гаилә ислам динен тота икән, аның намаз уку өчен мөмкинлеге булырга тиеш. Бу толерантлык кына түгел, бу – бергә яшәү культурасы. Һәркемнең үз почмагы булырга тиеш. Мин циркта намаз уку бүлмәсе ачылу башкаларга һәм оешманың эшчәнлегенә комачаулагандыр дип уйламыйм.

Мәдәни вакыйгаларга шактый бай булган 2022 елга йомгак ясап, мәдәният министры киләсе елның да шушы рухтарак узасын әйтте.

– 2023 ел Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Димәк, эшебез күп, ә яңа ел вакыйгаларга бай булачак, – диде ул, очрашуны йомгаклап.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

БАЛЫК ҺӘМ МАТЕМАТИКА ТУРЫНДА

Актаныш районында яшәүче 67 яшьлек Венера Гомәрова – кышкы суыкларда да бәке янында. Мәктәптә 42 ел математика укыткан мөгаллимә атнага берничә тапкыр ире белән балыкка йөри. Балыгы түгел, мәзәге кызык аның өчен.

Укытучы булып эшләгәндә, елга буйларында йөрергә әллә ни вакыты булмаган аның. Әмма шулай да балык тотуны бөтенләй онытып бетермәгән. Минзәлә районының Куян авылы кызы, инештә яулыктан, әбисенең алъяпкычыннан сөзгеч ясап, маймыч тотып үскәнгәме, бу шөгыль күңеленә аеруча якын. Абыйлары исә балыкны талдан үрелгән кәрҗин, каз оялары белән сөзгән. Аларга ялтырап торган чабаклар эләккән. Ишегалдында чистартканда, тавыкларның балыкны урлап качуы да кино кадры кебек исенә төшә Венера ханымның.

Ире Мөнир: «Әйдә, балыкка барыйк, термос белән чәй ал», – дип кенә тора икән. Соңгы вакытта килендәше Розаны да ияртеп, бергәләшеп Агыйделгә төшәләр. Бәкене ирләре тишә. Хатын-кызның моңа көче җитми. Калганы – үз кулларында. Бер балык та эләкмәгән, шул ук вакытта мулдан кергән чаклары да була. Балыкны ярма, камыр, суалчан ише җим белән кызыктыралар. Кармакка судак, чуртан, карплар каба. Венера апаның иң зур балыгы – 1,5 килолы, ә иң озыны – 30 сантиметр. Монысы нинди кармак белән тотуга да бәйле.

Укытучы башың белән су буенда кармак салып йөрисең, дигән сүзне бервакытта да ишетмәгән Венера Гомәрова. Киресенчә, кайдан вакыт табасың, дип аптырыйлар. Табигатьне ярата бит ул! Балыкчы ханым әйтүенчә, кармакка карап утырганда, дөнья мәшәкате каядыр ераккарак чигенеп тора. Кармак селкенсә, шунда балык та эләксә, кәеф икенче төрлегә әйләнә дә куя, ди. Эләкмәсә дә борчылмый, кыш көне битләр кызышып, җил ашап, аппетит ачылып кайтып керүне үзе бер рәхәткә тиңли. Көннәр буе суыкта туңып утырмыйлар, табигатькә чыгып керергә берничә сәгать тә җиткән аларга.

– Математикадан биремнәр чишкәндә зирәклек кирәк, ә балык тотканда? – дип сорадык Венера Гомәровадан.

– Су буенда мин математиканы онытып тордым. Балык тотканда әллә ни хәйләсен эзләгән юк. Җәйге яңгырдан соң балык бик шәп уйный, атмосфера басымы югарыга авышса, бик капмый. Кояшлы көнне су буенда рәхәт. Мин бит балыкчы түгел, күңел өчен генә йөрим, йөртүче булганга, – ди ул.

Математика турында сүз чыккач, уку темасына да сүз кузгаттык. Начар укучыга да әлеге фәнне яраттырып буламы икән?

– Математикага бөтенләй сәләте булмаган укучыдан отличник ук ясап булмый, билгеле. Ләкин фәнне яраттырырга мөмкин. Үз эченә бикләнгән, такта янына чыгудан курыккан, кул күтәреп җавап бирергә кыенсынган балалар була. Һәр баланың бер сәләте бар. Шуны күрә белергә, аның ышанычын үстерергә кирәк. Сорау биргәч, бала җавапны белсә, күзе очкынлана. Аның җавабын тыңласаң, мактап та җибәрсәң, түбәсе күккә тия. Әкренләп үзендә ышаныч арта, синең фәннән курыкмый башлый. Мәктәпне күптән тәмамлаган укучыларым бүген дә рәхмәт әйтә. Балалары, оныклары белән шөгыльләнүемне сорыйлар. Син укыткан фәнгә мәхәббәт синең балаларга булган мөнәсәбәтең аша килә, – ди әңгәмәдәшем.

Мәктәптән кабат балыкка күчтек. Гомәровлар аны тотарга гына түгел, ашарга да ярата. Венера апа балыкны кыздырып кына калмый, төрле ризыклар әзерли. Пирогын ясый, киптерә. Балык күп булмый, ди ул.

Венера Гомәрованың шәхси архивыннан

ВЕНЕРА ГОМӘРОВАДАН БАЛЫК КОНСЕРВЛАУ ЫСУЛЫ

1. Балыкны чистартып, эчен алып, башын-канатларын кисәм. Эре балык булса, 6–7 сантиметрлы кисәкләргә, кечкенәләрен урталай бүләм.
2. 2,5 кило балыкка 2,5 кашык тоз, 1 кило туралган суган, 1 чәй кашыгы төелгән борыч, лавр яфрагы, 400 грамм чистартылмаган көнбагыш мае салып, табакта болгатам.
3. Барысын бергә скороваркага салып, балык күмелер-күмелмәс су өстәп, утка куям. Кайнап сызгыра башлаганчы көчле, аннан сүрән утта 2 сәгать пешерәм. Сөякләре эреп бетә.
4. Сүндергәч, бераз ачмый торам. Кинәт ачсаң, атарга мөмкин.
5. Стерильләштерелгән банкаларга салып, банка авызына җиткәнче шулпа агызам. Капкачларны ябып, суытырга куям.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 392

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+